РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.03.2019 № 192-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда җәмәгать тәртибен саклау турында

“Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 1994 елның 21декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында" 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яки барлыкка килү куркынычы булганда җәмәгать тәртибен саклау максатларында Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://saby.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем өстемдә калдырам.

Җитәкче М.Р. Ишниязов

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитеты карары белән
04.03.2019 елдагы № 192-п

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау турында нигезләмә**

**1.** Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр (алга таба-гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килү яки барлыкка килү куркынычы булганда җәмәгать тәртибен саклау буенча чараларны билгели.

**2.** Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклау Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы Саба звеносы эшчәнлеге кысаларында гамәлгә ашырыла.

**3.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауны оештыру һәм тәэмин итү федераль законнар нигезендә Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге Саба янгын сүндерү-коткару гарнизоны бүлекчәләре белән хезмәттәшлектә тормышка ашыра.

**4.** “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 1994 елның 21декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы таләпләре нигезендә, Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге Гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта Россия Федерациясе Эчке эшләр Министрлыгының билгеләнгән боерыклары белән мәсьәләне хәл итә.

**5.** Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча муниципальара бүлегенең хәрби тәртип бүлекләре, хезмәтләре һәм төркемнәре эшчәнлеген идарә итү һәм координацияләү, РСЧС ТПның район звеносы идарәсе органнары белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру максатларында җәмәгать тәртибен саклау буенча оператив штаблар оештырыла. Штаблар гадәттән тыш хәл зонасында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча, гадәттән тыш хәлләр зонасында булган халык һәм оешмалар тарафыннан мәҗбүри үтәлергә тиеш карарлар эшләп чыгара.

**6.** Гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә җәлеп ителгән барлык көч һәм чаралар белән, алар арасында үзара хезмәттәшлекне оештыру, шул исәптән җәмәгать тәртибен саклау буенча да, гадәттән тыш хәлләрне бетерү җитәкчесе җитәкчелек итә.

**7.** Гадәттән тыш хәлләрне бетерү җитәкчесе итеп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы күрсәтмәсе яисә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү Комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә.